# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛЫН-БАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

2020 ел, 20 гыйнвар №171

**Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турындагы" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагы 2013 елның 25 июнендәге N 50-ТРЗ Кодексы, муниципаль берәмлек уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының 2016 елның 12 февралендәге 17 номерлы «Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы» карарының 1нче номерлы «Болын-Балыкчы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә» кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5.7 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

- сәяси партия белән, профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында,муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасын сайлап алучы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга,съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

- коммерцияле булмаган оешма белән (сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән идарә итүдә түләүсез рәвештә катнашу;

- Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

- муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешма идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә яклау;

- федераль законнарда каралган башка очраклар;

б) 5.7 пунктның түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктчасы белән:

"3.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;".

в) 18.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18.9. Әлеге нигезләмәнең 6, 7 статьяларында һәм 17.2 пунктында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу турындагы

мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булу чорын, отпускта булуын исәпкә алмыйча,гамәлгә ашырыла».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга,мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Болын-Балыкчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Болын-Балыкчы авыл җирлеге Башлыгы,**
**Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы Рәисе З. И. Сәйфуллина**